УДК 82.091

***И.К. Заһидуллин***

# САНКТ-ПЕТЕРБУРГТА ТАТАР ҖӘМГЫЯТЕ ҺӘМ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

Статья посвящена поездке знаменитого татарского поэта и публициста, общественного деятеля Габдуллы Тукая в город Санкт-Петербург (20 апреля – 6 мая 1912 г.). Дается краткая характеристика татарскому обществу столицы, известным личностям, сыгравшим большую роль в его становлении и развитии. Рассматриваются малоизвестные факты из жизни, круг общения Г. Тукая в Санкт-Петербурге, сделана попытка обобщающей оценки данного периода жизни и творчества поэта.
**Ключевые слова:** татарская литература, Габдулла Тукай, М. Бигиев, Санкт-Петербург, татарская городская махалля, возрождение начала XX века

The article is devoted to the trip of the famous Tatar poet and publicist, public figure Gabdulla Tukai to St. Petersburg (April 20 - May 6, 1912). A brief description is given of the Tatar society of the capital, famous personalities who played a major role in its formation and development. Little-known facts from the life and social circle of G.Tukai in St. Petersburg are considered, and an attempt is made to generalize the assessment of this period of the poet’s life and work.
**Keywords:** Tatar literature, Gabdulla Tukai, M.Bigiev, St. Petersburg, Tatar city mahalla, renaissance of the beginning. The twentieth century

## Башкаланың татар мәхәлләләре

Санкт-Петербургта татар диаспорасы формалашу берничә этапта бара.

Башкаланың беренче төзүчеләре арасында хәрби берләшмәләргә чакырылган йомышлы татарлар була. 1704 елдан башкала төзелешенә ил халкы, шул исәптән ясаклы татарлар җәлеп ителә башлый. 1710–1729 елларда Санкт-Петербург картасында төзүче, эшче татарлар, шулай ук әсир калмыклар, казаклар, төрекләр тупланган урын «Татар бистәсе» дип билгеләнә [29: 222–233].

Санкт-Петербург дөньяның иң тиз үсә торган шәһәрләреннән берсе булып, 1724 елга монда яшәүчеләрнең саны 100 мең кешегә җитә [20: VII]. 1869 елга ярты миллионнан артык кеше яшәсә, 1910 елны миллион ярым чиген уза [21: 90]. 1851 елны «Санкт-Петербург – Мәскәү» тимер юлы төзелеп бетү һәм 1862 елны Мәскәүдән Түбән Новгородка кадәр тимер юл тармагы булдырылу Рязань губернасы Касыйм өязе һәм Түбән Новгород губернасы татарларына башкалага йөрүне җиңеләйтә.

Төбәк тарихын өйрәнүче А.А. Бәхтияров татарлар башкалага Идел буйларыннан: Сембер, Пенза, Түбән Новгород һәм Казан губерналарыннан килгәннәр, дип искәртә. Авторның татарларның

төбәк принцибы буенча 10–30 кешене берләштергән зур булмаган артельләргә оешып яшәве хакындагы күзәтүләре дә фәнни кыйммәткә ия. Ул 1880 елларга иң зур татар артеленең, «эшче-хезмәтчеләрне» туплап, Кышкы сарайда эшләвен күрсәтә. Бәхтияров татарларда оешканлык, бердәмлекнең, бер-берсенә ярдәм итеп, аек тормыш алып бару рәвешен һәм традицияләрне саклау омтылышының көчле булуын билгели [6: 163–168].

1869 елга татарлар 2 мең кеше (шәһәрлеләрнең 0,3 % ы) булып, 1881 елга бу сан 2,7 меңгә (0,3 %), 1890 елга 3,5 меңгә (0,4 %) җитә, 1897 елга 5,4 мең кешегә кадәр үсә. 1910 елга исә башкалада 7,3 мең кеше (0,4 %) исәпләнә [32: 25] .

Читкә китеп эшләүчеләр өчен яңа күченүчеләрнең кавемдәшләре урнашкан, алар тарафыннан «үзләштерелгән» урыннарга килүе табигый була. Аларга монда даими эш яки туганнары, авылдашлары янында вакытлыча тору урыны табыла. Шулай татар җәмгыятенең мәдәни-көнкүреш рәвешен билгели торган «колонияләр» хасил була.

1722 елдан башлап саклы һәм йомышлы татарлар регуляр армиягә алына башлый, бер төркем түбән чиннар Санкт-Петербургта хезмәт итә. Хәрби муллалар үзләренең кул астындагы дин кардәшләрен, шул исәптән тыныч хезмәттәге кешеләрнең дини ихтыяҗларын да үтиләр. Аерым алганда, Гвардия корпусы ахуны Җиһангир Хантемиров тырышлыгы белән 1826 елны Волховка авылыннан 2 чакрым ераклыкта мөселман зираты ясау өчен патшадан рөхсәт алына [22: 466]. 1849 елны Гвардия корпусының өлкән ахуны Җәмлихан Рахманкулов Мәхкәмәи шәргыя карары белән Санкт-Петербургның өлкән ахуны итеп билгеләнә [1: 54].

1896 елны коры җир регуляр гаскәрендә хәрби муллалар вазифасын бетерү хәрбиләрнең рухани тормышына әлләни тәэсир ясамый. Алар бергәләп намаз уку өчен урын арендалау һәм руханиларга түләү чыгымнарын үз өсләренә алалар. 1905 елны хәрби ахун Х. Халитовның вафатыннан соң, хәрбиләр һәм отставкадагы чиннар үзләренең дини мәхәлләсен яңа, *өченче мәхәллә* итеп теркиләр [10: 134].

Рәсми теркәлгән мәхәллә булмау башкалада яшәүче мөселманнарның ислам тәртипләре белән көн итүенә артык йогынты ясамый. XIX гасыр башында күзәтүчән петербурглы И. Пушкарев болай дип яза: «Төрекләрнең, татарларның һәм, гомумән, Петербургта яшәүче мөселманнарның мәчете дә, мәхәлләсе дә юк, әмма сәүдәгәрләр арасында мулласы (указы булмаган мулла. – *И.З.*) булып, ул дин кардәшләренең өйләрендә гарәп һәм татар телләрендә тантаналы дини йолаларны башкара» [16: 466].

Санкт-Петербургта рәсми беренче мәхәллә 1822 елда, мулласы вазифасына булачак Оренбург мөфтие (1840–1862 еллар) Габделвахит Сөләйманов (1796–1862) билгеләнгәч теркәлә.

1869 елда яңа мулла итеп Түбән Новгород губернасы Сергач өязе Куй Суы авылы имамы Мөхәммәтшакир Юнысов сайлангач, Ря-

зань губернасы татарлары «Касыйм татарларының Бикбулатов хәйрия җәмгыяте» рәисе Хәбибулла Бикбулатов җитәкчелегендә икенче имам вазифасына Касыйм өязе Тәмгәнәй (Түбәнтау) авылыннан чыккан, Чутай авылы мәдрәсәсендә мөгаллим Гатаулла Баязитов (1847–1911) кандидатурасын тәкъдим итәләр. 1870 елны яңа оешкан икенче мәхәлләне Г. Баязитов җитәкли башлый.

Г. Баязитов, Оренбург Мәхкәмәи шәргыясе тарафыннан билгеләнеп, 1883–1905 елларда башкалада мәчет төзелешенә акча җыю белән шөгыльләнә, 1906 елдан әлеге мәчетне төзү комитеты әгъзасы буларак оештыру эшләренә зур өлеш кертә.

1911 елны, Гатаулла ахунның вафатыннан соң, рухани вазифаны аның улы Мөхәммәтсафа Баязитов (1877–1937), булачак Оренбург мөфтие (1915–1917) били.

Руханилар булу мөселманнарга, шул исәптән вакытлыча эшкә килгәннәренә дә, үзләренең гражданлык хәлләре актларын, никахларны, яңа туган балаларга исем кушуны тиз арада метрика кенәгәләренә теркәргә, вафат булганнарны зиратка күмәргә, гыйбадәт кылу урыннарында үгет-нәсыйхәт ишетергә мөмкинлек бирә. Намаз уку урыннарында (фатирларда) мәктәп эшли, анда малайлар, зур булмаган төркемнәргә оешып, башлангыч дини белем ала.

Гает бәйрәмнәрен уздыру өчен төрле оешмаларның заллары арендага алына.

Мәчетләр, ягъни этник-мәдәни һәм дини берләшү үзәкләре булмау, үз чиратында, җәмгыятьтә ныклы иҗтимагый багланышлар урнаштыруга комачаулый. Авыру, карт һәм ярдәмгә мохтаҗ дин кардәшләре турында кайгырту мәхәллә традицияләре, гаиләләр арасындагы горизонталь бәйләнешләр кысаларында тормышка ашырыла [2: 36].

## Санкт-Петербургның XX гасыр башы татар җәмгыяте

Россиядәге башка шәһәрләрдән аермалы буларак, XIX–XX гасырлар чигендә Санкт-Петербург мөселман җәмгыяте элитасы эшмәкәрләрдән түгел, бәлки хәрбиләрдән, чиновниклардан, морза-дворяннардан гыйбарәт булып, үзәк хакимият органнары белән хезмәттәшлек кимәлендә алар арасында күренекле урынны ахун Гатаулла Баязитов җитәкчелегендәге руханилар алып тора.

XX йөз башында шәһәр татарлары арасында социаль аерымлану көчәя. Җәмгыятьнең иҗтимагый-мәдәни тормышында дөньяви оешмаларның әһәмияте арта, бу исә дини-йола традицияләрен какшата. Монда яшәүче мөселманнарның күпчелеге өчен икетеллелек гадәти хәлгә әйләнә. Җәмгыять әгъзаларының абсолют күпчелеге дини һәм этник үзаңын саклый. Монда яңадан күченеп килүчеләрнең роле зур була. Башкалада үскән икенче буын татарлар, авыллардан кыз алып, руслашу куркынычын артка чигендерә. Авыллардан күченеп килгән беренче буын, электән яшәүчеләр белән чагыштырганда, ассимиляциягә нык каршы тора.

Россиядә барган модернизация һәм сәяси вакыйгалар башкалада татарларның мәдәни һәм иҗтимагый берләшүендә дә әһәмиятле роль уйный. Беренче рус революциясенең башлангыч чорында милли элиталарның социаль активлыгына эчке эшләр министры Святополк-Мирский тарафыннан игълан ителгән хөкүмәтнең «иҗтимагый көчләргә ышаныч сәясәте» зур йогынты ясый.

Мөселман иҗтимагый эшлеклеләре үзләренең проблемалары хакында мәҗлесләрдә фикер алышу һәм петицияләр бирү хокукыннан оста файдаланалар. Бу, үз чиратында, Санкт-Петербургка үтенеч тапшыру өчен депутатлар җибәрү хәрәкәтенә башлангыч бирә. Г. Исхакый күрсәтүенчә, Санкт-Петербургка килгән Кырым, Идел һәм Урал буе, Төркестан һәм Себер мөселманнары үзара танышып, мәҗлесләр оештыра, үз төбәкләренең проблемалары хакында сөйләшә башлый [17: 123]. Башкала җәмгыяте аларны үзләренә дәшә, Касыйм татарларыныкы булган тимер юл вокзаллары буфетларында бушка көндезге аш оештыра.

1905 елның башында Санкт-Петербургка Иркутск шәһәренең элекке имамы Лотфи Исхаков килә һәм шәһәр сәяси тормышының үзәгендә кайный башлый. Л. Исхаков[1] һәм Санкт-Петербург университеты студенты Ибниәмин Әхтәмов[2] шәһәргә килгән депутация вәкилләренә искиткеч зур ярдәм күрсәтәләр. Мөселманнар алардан башкала яңалыкларын ишетә, вакытлыча тукталу урыны адресларын таба h. б. [12: 128–1].

Депутацияләр вәкилләре аралашуларының зур бер нәтиҗәсе милләт проблемалары хакында бергәләп сөйләшү һәм уртак эш-гамәлләр планы булдыру фикерендә күренә. Үз сеңелесенең Муса Бигиев белән туен иҗтимагый-сәяси чара итеп файдалану уе Чистай мулласы, шул шәһәр депутациясе әгъзасы Ибраһим Камаловта Санкт-Петербургтагы төрле төбәкләрдән килгән кавемдәшләре белән очрашу барышында туа. Туй мәҗлесенә депутация вәкилләре, һәм алар гына да түгел, – 500 ләп кеше җыйнала. 20–22 майда Чис-

---

[1] Исхаков Лотфулла Фәткулла улы (?–1925) Оренбург өязе Яңа Муса авылында туа, Каһирәдә (Мисыр) укый. 1904 елның 17 мартында Мәхкәмәи шәргыя шәһадәтнамәсен ала. Мөселман хәйрия җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы, 1910 һәм 1912–1914 елларда аның идарәсе составында [14: 96].

[2] Ибниәмин Әхтәмов – Уфа губернасыннан, морза, юрист, 1895–1901 елларда Мәхкәмәи шәргыя сәркатибе булган Әбүссогуд Габделхак улы Әхтәмовның улы. 1898 елдан башкала университетында белем ала, студентлар хәрәкәтендә катнашканы өчен укудан чыгарыла, 1901 елны Санкт-Петербургта «Эшчеләр оешмасы комитеты» эше буенча кулга алына, өч ай төрмәдә утырганнан соң Уфага озатыла, анда тыелган әдәбият саклаганы өчен кабат кулга алына. 1903 елны эсерлар партиясенә керә. 1907 елны Санкт-Петербург университетының табигыять, 1910 елны хокук факультетларын тәмамлый, 1910–1911 елларда Уфа губернасы округ судының ант биргән ышанычлысы вазифасын башкара, IV Дәүләт думасына сайлана, андагы мөселман фракциясенең сәркатибе була, 1913–1915 елларны башкалада С.С. Җантурин белән бергәләп «Милләт» газетасын чыгара [17: 254; 18: 81].

тайда туй һәм яңа форматта гомуммилләт мәсьәләләрен тикшерү уза [13: 14–23].

1906 елның 13–26 гыйнварында, шәһәрдә үткәрергә рөхсәт алынмаган хәлдә, II Бөтенроссия мөселманнары съезды уза.

1905 елның 7 июнендә Г. Баязитовның «Нур» газетасын чыгару хакындагы үтенече канәгатьләндерелә. Ахунның күп еллар дәвамында Чит илләр министрлыгының Азия департаментында укытучы булып эшләве, чиновниклар белән дустанә мөнәсәбәтләре аңа бу эштә ярдәм итә [19: 227]. Татарча газетаның беренче номеры 1905 елның 2 сентябрендә дөнья күрә. Бу вакыйганы татар зыялылары шатланып каршы ала [4: 41–43].

Бу яңалыкны ишеткәч, 20 яшьлек Г. Тукай болай дип яза:

*Шималь яктан чыгып бәркъ, орды бер нур,*
*Зыясыннан әһали улды пәрнур.*
*Мотабикъдер мөсәммасенә исме,*
*Мөнасыйбдыр дәхи исменә җисме.*
*Нә дәүләт милләтә, нә бәхт вә талигъ,*
*Бу көз төньяктан улды шәмес талигъ* [28: 45].

Көн кадагына суккан милли иҗтимагый-мәдәни мәсьәләләр буенча бу басма битләрендә, Г. Баязитовтан тыш, Дәүләт думасы әгъзалары Г. Еникеев, С. Максуди, С. Максудов, Ш. Мәхмүтов, К.-М. Тәфкилев, язучылар Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Кәрими, Р. Фәхреддин һ. б. чыгыш ясый. Рус һәм татар газеталарыннан яңалык-хәбәрләр белән беррәттән, анда хикәяләр, фәнни-популяр һәм бәхәсле мәкаләләр дөнья күрә. Аерым алганда, «Нур» беренче булып әдәби татар теле проблемасына кагыла [5: 254–267]. Баштагы чорда газета атнага бер, соңрак айга берничә сан басылып килә. 1906 елны Дәүләт думасына сайлаулар вакытында газета конституцион демократлар партиясе өчен тавыш бирергә чакыра, либераллар лагерена карый [31: 90–92]. Соңрак ул «уңга», хакимият яклылар ягына авыша. 1911 елгы газетадагы соңгы язмасында Г. Баязитов кавемдәшләрен үзара тарткалашуларны туктатырга, алгарыш һәм милли мәдәниятне үстерү мәсьәләсенә бергәләп игътибарны тупларга чакыра, татар милләтенең киләчәккә башка юлы юк дип белдерә [5: 262].

Санкт-Петербургта Дәүләт думасы депутатларының эшчәнлеге, биредә иҗтимагый-сәяси тормыш кайнау һәм башка факторлар татар җәмгыятендә сәяси карашларның ике чиккә аерылуына китерә. Аларны прогрессистлар (алгарыш яклылар) һәм консерваторлар (тотрыклылык яклылар) дип атап булыр иде. Консерваторлар лагерен Г. Баязитов җитәкли.

Алгарыш яклы фикердәшләрнең аралашу клубы шикеллерәк булып, Казан урамы, 40 йортта урнашкан Мөселман хәйрия җәмгыяте аерылып чыга. Консерваторлар ягыннан руханилар алгы сызыкта булганга, җәдитчеләрнең җәмәгать намазларын, дини чараларны

үзләренең сәяси карашын уртаклашкан руханилар белән уздыру теләге табигый тоела. Революцион хәрәкәтләр көчәйгән 1905 елны җәмгыять Шәһәр башлыгына оешманың Уставына ярлы мөселманнарның дини ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен рухани тоту турындагы пункт кертергә рөхсәт сорап мөрәҗәгать итә. Күрәсең, шуның белән прогрессистлар мөстәкыйль мәхәллә булдырырга өметләнәләр. 1906 елның 19 августында татарларның үтенече канәгатьләндерелә. Әмма матди кыенлыклар булу сәбәпле, Җәмгыять үзенең планын тормышка ашыра алмый.

1907 елны мөселманнарның бу төркеме Шәһәр башлыгыннан, бинаның сыйдырышына бәйле, 120 дән артык кеше җыелмаган очракта, җомга көнне көндезге намазларны уздырырга рөхсәт алуга ирешә. Намаз урыны итеп 150 кеше сыйдырышлы Мөселман хәйрия җәмгыяте бинасы тәгаенләнә, шунда ук рус-татар мәктәбе эшләп килә. Аларның гамәлләре рәсми теркәлгән мәхәлләләрнең икесенең руханилары тарафыннан гаепләнә. Соңгылары моны шәригатькә каршы килә дип күрсәтәләр.

1907 елдан башлап прогрессистлар ел саен бина арендалап, Рамазан һәм Корбан гаетен үзләре уздыра башлыйлар. Бу эшкә башкаладагы милли мәктәпләрнең берсендә туган тел мөгаллиме, жандармериягә мөселманнар арасында «конституцион-демократик» идеяләр агитаторы, башкалада «рухани вазифа алырга омтылучы» буларак мәгълүм мулла Лотфулла Исхаков чакырыла. Аерым кешеләрнең һәм руханиларның хакимияткә моны туктатуны сорап мөрәҗәгать итүләре уңышка китерми. Корбан бәйрәмендә «дөньяви» чаралар исә Җәмгыять бинасында оештырыла, анда хәйрия җәмгыяте файдасына акча да җыела [11: 139–142].

Милли үзаң үсү шартларында Санкт-Петербургта мәктәпләр челтәре формалаштыру проблемасы да XX йөз башында мөселманнар өчен хәлиткеч әһәмияткә ия була. 1912–1913 уку елында Санкт-Петербургта өч шәхси татар мәктәбе эшли: Мөселман хәйрия җәмгыятенең татар-рус мәктәбе (1906 елдан): ике җенестән дә булган 70 бала белән 3 укытучы шөгыльләнә; Я.А. Мухлионың сәүдәгә өйрәтүче шәхси мәктәбе: 3 укытучы 30 кешегә белем бирә (1912 елны ачыла) һәм С. Ижбердиев мәктәбе: 1 укытучы 15 баланы укырга-язарга һәм дин нигезләренә өйрәтә. Болардан тыш, мәхәлләләрнең җәмәгать намазы укый торган биналарында башлангыч мәктәпләр эшли. Сәүдәгәрләрнең һәм руханиларның балалары, кагыйдә буларак, милли белем алганнан соң, шәһәрнең рус урта уку йортларына укырга керәләр.

Илнең төрле төбәкләреннән яшьләрнең башкалага югары уку йортларына белем алырга килүен татар җәмгыятендәге яңалык буларак күрсәтергә кирәк. Әйтик, 1909 елны Петербург университетында – 55, 1912 елны 47 мөселман студент хисаплана [11: 306]. Гыйлем туплаучылар арасында кызларның зур булмаган төркеме күренә башлый. Бестужев хатын-кызлар курсларында (1907–1908 уку елында

4 кеше [9: 11] укый, 1909 елны хокук факультетындагы 243 кешенең 0,4 % ы мөселман кызлар, физика-математика факультетындагы 608 кешенең – 0,3 % ы [24: 3], Н.П. Раевның югары тарих-әдәбият һәм хокук хатын-кызлар курсларында, медицина институтында, педагогик курсларда, шулай ук Психоневрология институтында, Лесотехник курста, М.А. Лохвицкой-Скалонның Югары табигыятьфәнни курсларында һ. б. да була алар [3: 51–52; 8: 121–127].

1912 елның гыйнвар уртасында Дәүләт думасы депутатларын, башкала зыялылары вәкилләрен, муллаларны күпләп тентү һәм кайберләрен судсыз-нисез генә, административ юл белән вазифаларыннан азат итү сәбәпле, башкала хакимияте янына килгән Оренбург мөфтие М. Солтанов җитәкчелегендә Идел буе мөселманнары депутацияләре әгъзалары катнашында Дәүләт думасы депутаты Галиәскәр Сыртланов фатирында киңәшмә үза [25: 46].

**Г. Тукайның Санкт-Петербургка килү тарихы**

Габдулла Тукайның 1912 елны Россия империясе башкаласына баруы аның бик тиз көчәеп баручы сулыш органнары авыруыннан дәва эзләп башланган сәяхәтенең бер өлеше кебек күзаллана. Яшь организм инде авыруга каршы тора алмыйча, бу шагыйрьгә күп кыенлыклар китерә, аның күнегелгән яшәү рәвешенә дә, иҗат эшенә дә киртә куя. XX гасыр башында бу юнәлештә дәвалау методикалары һәм чаралары ягыннан медицина шактый чикләнгән булып, сулыш юллары авыруыннан җәфа чигүчеләргә кымыз белән дәвалану киңәш ителә. Традицион рәвештә җәй көннәрендә илнең төрле төбәкләреннән Уфа һәм Оренбург губерналарына, дәва эзләп, күпсанлы авырулар җыела, мондый төркемнәр тупланган поездлар килеп туктый торган шәһәрләрдә дә инфекцион хәл кискен дип хисаплана. Танышларының сөйләве буенча, шагыйрь дәва үзлекләре ягыннан иң яхшыларыннан хисапланган үзәкнең Оренбург даласында, Троицк өяз шәһәрендә урнашканын белә. Бу шәһәрдә икътисади яктан көчле һәм иң эреләрдән булган татар җәмгыяте яшәп килә. Нәкъ менә Троицк шагыйрь сәяхәтенең ахыргы ноктасы булырга тиеш дип планлаштырыла. Шуңа да Тукайның күпләр өчен көтелмәгән рәвештә, бик иртә, Идел буйлап елга юлы ачылуга ук, кымыз сезоны башланганчы, Казаннан китүен без авыру һәм туктаусыз ютәл чиктән тыш көчсезләндергән шагыйрьнең тизрәк дәвалану процедуралары алу, физик газаплардан котылу теләге белән аңлатабыз. Яшь шагыйрь яшәү һәм иҗат итү теләге белән яна, Аллаһтан өч кенә ел булса да гомер сорый [7: 649].

Казаннан ул каты авыру, үз хәлен җиңеләйтү өмете сүнмәгән кеше булып юлга кузгала.

Сәяхәткә әзерләнеп, Г. Тукай гардеробын яңарта: инглиз модасы белән тектерелгән яңа демисезон пальто, алман (немец) эшләпәсе, яңа таяк сатып ала. Бер сүз белән әйткәндә, кыяфәтен тәртипкә китерә [7: 644].

1912 елның апрель уртасында Г. Тукай «Фультон» пароходына утырып, Самара шәһәренә юнәлә. Елга вокзалында аны шагыйрь белән актив хезмәттәшлек иткән, «Ялт-Йолт» сатирик журналының редакторы Әхмәт Урманчиев озатып кала.

Кичкә таба Самарага килеп төшкән, акча ягыннан кысынкылык кичергән Тукай монда ике тапкыр алдана. Извочник, күрәсең, пассажирның яңа кием-салымына һәм зыялы кыяфәтенә карап, яки башка сәбәпләр белән, иң начарлардан булмаган кунакханәгә илтү үтенечен бөтенләй башкача үти: аны шәһәр уртасында, Дворяннар урамында урнашкан иң кыйммәтле, беренче класслы ресторанлы «Бристоль» кунакханәсенә китерә. Тукай иң очсызлы бүлмәгә урнашырга мәҗбүр була, әмма барыбер 1 сум 25 тиен түли. Аннары үзеннән көлеп: әгәр очсызлы кунакханәгә урнашкан булсам, Самарада бер атна яшәгән булыр идем, әмма «Бристольдә» төн генә кунып була, дип сөйли…

Урнашып, иркен бүлмәдә ялгызы каласы килмичә һәм әңгәмәдәш эзләп, шагыйрь кич соң гына үзенең килүе хакында «Икътисад» журналының редакторы имам Фатих Мортазинга хәбәр итәргә уйлый һәм тагын бер тапкыр алдана. Извозчиктан Самара мулласының адресын белү-белмәвен ачыклагач, Г. Тукай юл бәясен сорый. Извозчик 40 тиен дип әйтә һәм өстәп 10 тиен таләп итә. Ат кунакханә почмагыннан борылгач ук туктый, Ф. Мортазин үз өе янында урамда булып чыга һәм бер сәгатьтән килергә вәгъдә бирә. Тукай, тагын 50 тиен түләп, кунакханәгә кайта. Соңрак бу барып-кайтуның җәмгысе 25 тиен, шагыйрь түләгәннең дүрттән бере торганлыгы ачыклана.

Тукай үзенең кунакханә номерында Фатих Мортазин белән төрле темаларга сөйләшеп, төнге уникегә кадәр утыра. Икенче көнне, 16 апрель иртәсендә, Самараның тимер юл вокзалыннан поездга утырып, Уфага юл тота. Аны Мортазин мәдрәсәсе шәкертләренең берсе озата төшә.

Губерна шәһәренә килеп төшкәч, извозчик яллап, Тукай туптуры үзенең яхшы танышы, «Сабах» нәшриятының китап кибетендә эшләүче Хәбибрахман Зәбиригә китә. Аның янына бару максаты – Уфада кыйммәт булмаган кунакханә табып урнашу. Казаннан кадерле кунак килүгә бик шатланган Х. Зәбири аңа «Сабах» китап кибетенең икенче катында урнашкан, китап саклау урыны булып хезмәт иткән бүлмәдә яшәргә тәкъдим итә. Г. Тукай килгән вакытта бу иркен, коры һәм җылы бүлмә ярым буш булып, бинаның беренче катында кухня эшләп тора. Үзенә карават куйдырып, кунак бушлай тукталу урыныннан канәгать кала [27: 169–173].

Кымыз белән дәвалану сезоны бер айдан соң гына ачылачагын белгәч, ул танылган дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе Муса Бигиевтән ел башында алган Санкт-Петербургка чакыру хакында исенә төшерә. Г. Тукайның үз сүзләренә караганда, ул башта башкалага күз көне, Троицкида сәламәтлеген ныгытканнан соң барырга җыенган була («мин Петербурга баруны көзгә, кымыз эчеп хәлләнгән чакга кичектермәкче идем» [27: 176]).

М. Бигиев[1] тарафыннан берничә имза куеп язылган ике хатта шагыйрь мондыйрак шартлар вәгъдә итеп чакырыла:

– чакыручы як хисабына кунакханә, андагы эчемлекләр;
– яңа киемнәр комплекты бүләк итү;
– Санкт-Петербургка юл чыгымнары өчен акча җибәрү;
– кайтырга бушлай билет алып бирү [7: 641];
– Финляндиягә сәяхәт итү[2];
– табиблар белән консультация оештыру [15:668].

Күрәсең, Петербург татарлары төркеме күренекле шагыйрьне башкалага барлык чыгымнарны да үз өсләренә алып чакырырга ниятли. Моңа кадәр беркемнең дә мондый илтифат күрсәтеп чакырганы булмаганга, М. Бигиев хаты Тукайда кызыксыну уята. Юлга чыгу карары кабул итүдә, шиксез, хатның авторы – танылган гарәп теле, Коръән, мөселман дин белгече, Г. Тукай белән яхшы мөнәсәбәтләрдәге М. Бигиев булу хәлиткеч роль уйнагандыр.

Кәбир Бәкернең «Тукай Петербургта» дигән басмасы белән танышкач, 1914 елны Муса Бигиев «Вакыт» газетасы редакторы Фатих Кәримигә хат язып, авторның кайбер бәяләмәләрен тәнкыйтьли, Г. Тукайны башкалага чакыру һәм аның Петербургта яшәве хакында үз күзаллавын аңлата: «Дөрест, өч-дүрт адәм без Габдулла әфәндене дәгъвәт итмеш идек. Казанда Габдулла әфәнденең гайәт аяныч хәлләре без[гә] мәгълүм иде. Дәгъвәт (чакыру) у[л] мөшкел хәлләрдә Габдулла әфәндене азад итмәк касд (ният) иде. Бән Габдулла әфәнденең квартирасыны Лотфулла әфәнде һәр көн биш бутылка пивосыны, Галим әфәнде Максудов һәркөнге ашыны-чәене, янә берничә адәм

---

[1] Муса Бигиев 1873 (яки 1875) елны Ростов-на-Дону шәһәрендә туа. Башлангыч белемне гаиләдә ала, күпмедер вакыт Казандагы Апанай мәдрәсәсендә укый, Ростов-на-Дону шәһәрендә реаль лицей тәгәлли, аннары Бохарада укый. 1896 елны Каһирәдәге әл-Әзһәр университетына укырга керә, Мәккәдә һәм Мәдинәдә гыйлем туплый, Һиндстанга барып чыга, Бомбейда укый, кабат Каһирәгә кайта.

1904 елны М. Бигиевнең Каһирәдәге әл-Әзһәр университетын тәмамлап туган иленә әйләнеп кайтуы һәм Санкт-Петербургта төпләнүе башкалада иҗтимагый-сәяси хәрәкәтләрнең гаять активлашкан чорына туры килә. Бу хәрәкәтләрнең төп вәкилләре – рус либераллары хәкүмәткә оппозиция хасил итә. М. Бигиев мөселманнарның иҗтимагый хәрәкәтенә катнашып китә, 1905 елның беренче яртысында башкалага агылган мөселман депутацияләре белән аралаша, «Иттифак әл-мөслимин» партиясен оештыру документларын – программаларын һәм уставын төзүгә зур өлеш кертә, татар вакытлы матбугатына күпсанлы мәкаләләр яза.

Санкт-Петербругта М. Бигиев Габдерәшит Ибраһимов белән бергәләп атна саен чыга торган «Өлфәт» газетасын ача (1905 елның 11 декабре – 1907 елның 9 июне). Хакимият аны ябып куйгач, Казанга күченә, монда 1909 елга кадәр мөселманнарның дини һәм иҗтимагый проблемаларына кагылышлы хезмәтләрен бастыра. Бу хезмәтләр татар зыялылары арасында аңа танылу алып килә.

1909 елдан ул Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. Әмма 1910 елны М. Бигиев Санкт-Петербургка әйләнеп кайта, анда фикъһ һәм дин белеме буенча эзләнүләрен дәвам итә. 1912 елны Коръәннең татарчага тәрҗемәсен төгәлли [30: 378].

[2] Кайбер чыганаклар буенча, М. Бигиев шагыйрьне Выборг губернасындагы «Хәлилә» император дәваханәсенә җибәрергә планлаштыра. Әмма бай татарлар бу проектны финансламыйлар [25: 54].

башка хаҗәтләрене тәмамы кылачак идек. Казанда корректорлык шәрәфенә канәгать кылуб, Габдулла әфәнде Петербургта у[л] вакыт интишары фараз кылынмыш (нәшер итәргә уйлаштык) җәридәдә (газетада) исмән генә мөхәррирлек хезмәтенә, әлбәттә, рази улыр да, Петербургда бәлки калур хыялында идек» [22: 204][1].

Тукай Уфадан М. Бигиевкә чакыруны кабул итүен һәм Санкт-Петербургка юлга чыгачагын әйтеп, телеграмма суга. Ике көн узгач, Х. Зәбири Лотфулла Исхаковтан Г. Тукайга юл чыгымнары өчен 25 сум акча бирүне үтенгән телеграмма ала. Х. Зәбири шагыйрьне башкалага озату мәшәкатьләрен дә башкара: поездга билет алып, 18 апрельдә [27: 376] аны Уфа вокзалыннан, Эстәрлетамак сәүдәгәре-юлдашы белән Николаев вокзалында Санкт-Петербургка бара торган поездга күчереп утырту турында килешеп, Мәскәүдән җибәреләсе телеграмма текстын Тукайның кулына бирә [15: 668–669].

Соңрак Г. Тукай Бәкергә[2] үзен ни өчен Санкт-Петербургка чакыруларының асыл сәбәбен белмәвен әйтә, чөнки бу хакта аңа бернинди дә аңлатма бирелми. Бәкер фикеренчә, 1912 ел башында мөселманнар арасында яшь дин әһелләре төркеменең татар телендә «Хәбәр» яки «Сүз» дигән яңа газета чыгарырга ниятләве турында сүзләр йөри[3]. Иң кызыгы, баш редактор итеп Г. Тукай чакырыла имеш, диләр. Чынлап та, әлеге имеш-мимешләр таралу М. Бигиевнең Казанга бер-бер артлы ике хат җибәрү вакытына туры килә. Бәкер һәм Кәрим Сәгыйть язганча[4], әлеге хатларны алып 2–2,5 ай узгач кузгалган Г. Тукай башкалага килгәндә, әлеге идея нинди дер сәбәпләр аркасында актуальлеген югалта [7: 642; 23: 117].

*(Дәвамы бар)*

**Әдәбият**

1. *Азаматов Д.Д.* Оренбургское магометанское духовное собрание в конце XVIII–XIX вв. Уфа: Китап, 1999. 194 с.

---

[1] Күрәсең, М. Бигиев шагыйрьнең Казаннан китәргә теләвеннән хәбәрдар булган. Ул бу хакта үзенең якыннарына 1910 елларда күп сөйләгән [23: 116].

[2] Бәкер Кәбир (1885–1944) Оренбург губернасы Түбән Озерки авылында туа. Шәрык телләрен белә. 1905–1907 елларда – «Нур» газетасы, аннары «Әлислах» (Казан) газетасы редакциясендә эшли. 1910 елдан – III Дәүләт думасының мөселман фракциясе сәркатибе. Беренче Балкан сугышы вакытында, 1912 елны бер төркем шәфкать туташлары белән бергә Санкт-Петербургтан Төркиягә, яралыларга ярдәм күрсәтергә китә. 1913 елны Казанга әйләнеп кайта, аннары Оренбургта «Вакыт» газетасы редакциясендә эшли. 1917 елны «Олуг Төркестан» газетасын чыгаруны оештыра.

[3] Бу проект ел ярым узгач тормышка аша. 1913 елның 22 октябрендә Гаяз Исхакый Санкт-Петербургта «Ил» газетасын чыгара башлый. 1914 елның ноябрендә редакция Мәскәүгә күчә. 1916 елның декабре – 1916 елның июнендә газета «Сүз» дип атала [25: 37].

[4] Кәрим Сәгыйть (1883–1939) – журналист, тәнкыйтьче, соңыннан укытучы. Вакытлы матбугатта «Кәрим Сәгыйд», «К. Сәгыйд», «Петербург корреспонденты», «К.С.» һәм башка имза, псевдонимнар белән мәкаләләр бастыра. Совет елларында Фәннәр академиясе системасында гыйльми хезмәткәр булып эшли. «Тукай тормышыннан истә калганнар» исемле истәлекләр авторы [23: 115].

2. *Аминов Д.А.* Татары в Ст. Петербурге. Исторический очерк. СПб.: «Альд», 1994. 49 с.

3. *Амирханов Р.У.* Некоторые особенности развития народного образования у татар в дооктябрьский период // Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. Казань, 1992. С. 22–60.

4. *Амирханов Р.У.* Татарская дореволюционная пресса в контексте «Восток – Запад» (на примере развития русской культуры). Казань, 2002. 238 с.

5. *Әмирхан Р.* Иманга тугрылык. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 336 б.

6. *Бахтияров А.А.* Брюхо Петербурга. Очерки столичной жизни. Л., 1994. 224 с.

7. *Бәкер Кәбир.* Тукай Петербургта // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. 1 т. Б. 632–662.

8. *Биктимирова Т.А.* Ступени образования до Сорбонны. Казань: Алма-лит, 2003. 184 с.

9. Высшие женские курсы (основаны в 1876 г.). Отчет за 1907–1908 г. СПб.: тип. Ю.Н. Эрлих, 1909. 75 с.

10. *Загидуллин И.К.* Исламские институты в Российской империи: Мусульманская община в Санкт-Петербурге. XVIII – начало XX вв. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2003. 179 с.

11. *Загидуллин И.К.* Мусульманское богослужение в учреждениях Российской империи (Европейская часть России и Сибирь). Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2006. 462 с.

12. *Загидуллин И.К.* Национальное движение мусульман Волго-Уральского региона в начальный период революции 1905–1907 гг.: монография. Казань: ООО «Центр инновационных технологий», 2019. 256 с.

13. *Загидуллин И.К.* Татары Чистополя в петиционной кампании мусульман 1905 г. // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2024. №2. С. 14–23.

14. *Загидуллин И.К., Тагирджанова А.А.* Исхаков Лутфулла Феткуллович // Ислам в Санкт-Петербурге. Энциклопедический словарь / Коллект. авторов; сост. и отв. ред. Д.З. Хайретдинов. М.; Н. Новгород: Изд. дом «Медина», 2009. С. 96.

15. *Зәбири Хабиберахман.* Габдулла әфәнденең Уфадан Петербурга баруы // Тукай – ядкярләрдә: 2 томда / төз.: Р.Ф. Исламов, Җ.С. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2015. 1 т. Б. 668–670.

16. Исторические кладбища Петербурга: Справочник-путеводитель / [Санкт-Петербург. фонд культуры; сост.: А.В. Кобак, Ю.М. Пирютко]. СПб.: Изд-во Чернышева, 1993. 639 с.

17. *Исхаков С.М.* Ахтямов Ибниамин Абуссугутович // Башкирская энциклопедия. Т. 1. Уфа, 2005. С. 254.

18. *Исхаков С.М.* Первая русская революция и мусульмане Российской империи. М.: Наука, 2007. 400 с.

19. *Каримулин А.Г.* Татарская книга пореформенной России. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. 318 с.

20. Первая всеобщая перепись населения Российской империи 1897 года. Т. XXXVII. Город С.-Петербург. Тетрадь 2 и последняя / под ред. Н.А. Тройницкого. СПб., 1903. XXXII, 261 с.

21. *Рашин А.Г.* Население России за 100 лет (1811–1913 гг.). Статистические очерки. М.: Гос. стат. изд-во, 1956. 324 с.

22. *Рәхимова А.* «Шу мәктүбем сүзләре сезә әманәтдер...» // Гасырлар авазы – Эхо веков. 1996. № 1/2. Б. 200–205.

23. *Сәгыйдова Э. Г.* Кәрим Сәгыйд архивыннан // Казан утлары. 1968. №4. Б. 115–119.

24. Слушательницы С.-Петербургских высших женских, Бестужевских курсов. По данным переписи (анкеты), выполн. статистическим семинарием в ноябре 1909 г. / Стат. семинарий С.-Петерб. высш. жен. курсов. СПб., 1912. XX, 144 с.

25. *Тагирджанова А.* Книга о Мусе-эфенди, его времени и современниках. Сборник историко-биографических материалов. Казань, 2010. 576 с.

26. *Тагирджанова А.* Максутов Мухаммед-Алим Рахимович // Ислам в Санкт-Петербурге. Энциклопедический словарь. М., 2009. С. 125.

27. *Тукай Г.М.* Шигырь (Шималь яктан...) // Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 1 т.: шигъри әсәрләр (1904–1908) / төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл.: Р.М. Кадыйров, З.Г. Мөхәммәтшин. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 45.

28. *Тукай Г.М.* Мәкаләи махсуса // Тукай Г.М. Әсәрләр: 6 томда. Академик басма. 5 т. : мәсәлләр, балалар өчен хикәяләр, автобиографик повесть, юльязмалар, хатлар (1903–1913) / төз. һәм аңл. әзерл.: Г.А. Хөснетдинова, Г.М. Ханнанова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. Б. 167–183.

29. *Файзрахманов И.З.* Татарский след на берегах Невы: из истории строительства Санкт-Петербурга в первой четверти XVIII в. // Научный Татарстан. 2009. № 2. С. 222–233.

30. *Хайрутдинов А.Г.* Бигиев Муса // Татарская энциклопедия / гл. ред. М. Хасанов. Т. 1. А–В. Казань: Институт татарской энциклопедии, 2002. С. 378.

31. *Шангараев Р.* Газета «Нур» как интегрирующий татарское общество в российское социокультурное пространство элемент // Вестник Казанского государственного университета культуры и исскуств. 2007. № 2. С. 90–92.

32. *Юхнева Н.В.* Этнический состав и этносоциальная структура населения Петербурга, вторая половина XIX – нач. XX в. Стат. анализ / под ред. К.В. Чистова. Л.: Наука: Ленингр. отд-ние, 1984. 223 с.

***Заһидуллин Илдус Котдус улы***,
*тарих фәннәре докторы, доцент, ТР ФА Исламны өйрәнү үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре*

***Загидуллин Ильдус Котдусович,***
*доктор исторических наук, доцент, старший научный сотрудник Центра исламоведческих исследований АН РТ*

*zagik63@mail.ru*